| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 15.12.2016 г. Казань № 5-59/тэ

2017-2019 елларга «Таткоммунэнерго» Республика җитештерү берләшмәсе» акционерлар җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Таткоммунэнерго» Республика җитештерү берләшмәсе» акционерлар җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, календарьга бүлеп җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 гыйнвареннән 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2017-2019 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифларны формалаштыру өчен, җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына тәгаенләнеп, озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрларын әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп билгеләргә

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 15.12.2016 № 5-59/тэ
карарына кушымта

2017-2019 елларга календарьга бүлеп «Таткоммунэнерго» Республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга бирелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салучы оешма исеме, тариф төре | Ел | Су | Басым астында алынган пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 дән 2,5 кг/см$^2$-га кадәр | 2,5 дән 7,0 кг/см$^2$ га кадәр | 7,0 дән 13,0 кг/см$^2$-га кадәр | свыше 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» Республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифларга дифференциация ясалмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум./Гкал | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 1181,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 1231,36 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 1231,36 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 1251,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2019 алып 30.06.2019 кадәр | 1251,92 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 алып 31.12.2019 кадәр | 1310,99 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге